ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

25 апрель 2018 ел | № 2305

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендәге 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе, шәһәр уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын (алга таба – административ регламент) кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезнамәне раслау турында» 2014 елның 8 маендагы 2668 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 8283 нче карары;

3) Башкарма комитетның «Эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 1 июнендәге 3469 нчы карары;

4) Башкарма комитетның «Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өлкәсендә Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 31 мартындагы 1440 нчы карары;

5) Башкарма комитетның «Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өлкәсендә Башкарма комитетның аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 10 февралендәге 667 нче карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастыруны, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Управление делопроизводству
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 25 апрелендәге
2305 нче карарына
кушымта

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның
административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Административ регламент эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәгәндә Башкарма комитет финанс идарәсенең (алга таба – финанс идарәсе) административ процедуралары һәм административ эш итүләренең срокларын һәм эзлеклелелеген билгели.

2. Муниципаль контроль финанс идарәсенең функциясе булып тора.

3. Финанс идарәсе контроль буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлар үтәлешенә контрольне;

2) бухгалтерлык хисабының тулылыгына һәм дөреслегенә контрольне;

3) «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 99 маддәсенең 8 бүлегендә каралган позицияләр буенча сатып алулар өлкәсендә эчке муниципаль финанс контролен.

4. Тиңдәш контроль чарасы дигәндә финанс идарәсе тарафыннан үткәрү планлаштырыла торган контроль объекты эшчәнлегенә карата аның кысаларында башка дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан контроль гамәлләре үткәрелә (үткәрү планлаштырыла) торган контроль чаралары аңлашыла.

Административ регламентта кулланыла торган башка төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Бюджет кодексындагы мәгънәдә файдаланыла.

5. Муниципаль контроль түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Бюджет кодексы («Собрание законодательства Российской Федерации», 03.08.1998, №31, ст. 3823; «Российская газета», 12.08.1998 №153-154);

2) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон («Собрание законодательства Российской Федерации»,

06.10.2003, №40, ст. 3822; «Парламентская газета», 08.10.2003, №186, «Российская газета», 08.10.2003 №202);

3) «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяжларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль закон («Собрание законодательства РФ», 08.04.2013, №14, ст. 1652, «Российская газета», №80, 12.04.2013) (алга таба – 44-ФЗ санлы Закон);

4) Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре өчен бухгалтерлык хисабы счетларының Бердәм планын һәм аны куллану инструкциясен раслау турында» 2010 елның 1 декабрендәге 157н санлы приказы («Российская газета», №8, 19.01.2011) (алга таба – РФ Финанс министрлыгының 2010 елның 1 декабрендәге 157н санлы приказы).

6. Муниципаль контроль буенча эшчәнлек планлы һәм планнан тыш эшчәнлеккә бүленә һәм законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, профессиональ компетентлылык, нәтиҗәләр дөреслеге, ачыклык принцибына нигезләнә.

7. Муниципаль контроль финанс идарәсенең вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның исемлеге Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы боерыгы белән раслана.

8. Муниципаль контроль предметы булып Административ регламентның 9 пунктында каралган муниципаль контроль объектлары тарафыннан федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән таләпләрне, шулай ук бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләре һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы өлкәсендәге муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

9. Бюджет законнары нигезендә түбәндәгеләр муниципаль контроль объектлары булып тора:

1) бюджет акчалары белән баш эш итүчеләр (эш итүчеләр, алучылар), бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);

2) муниципаль учреждениеләр;

3) муниципаль унитар предприятиеләр;

4) устав (җыелма) капиталларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге катнашында хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең өлеше (кертеме) белән коммерцияле оешмалар;

5) юридик затлар (муниципаль учреждениеләрдән, муниципаль унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында муниципаль берәмлек катнашында хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләрдән,

шулай ук устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) белән коммерцияле оешмалардан тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар – Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акчалар бирү турында килешүләр (килешенүләр) шартларын үтәү, шулай ук күрсәтелгән килешүләрне (килешенүләрне) үтәү максатында төзелгән контрактлар (килешүләр, килешенүләр) һәм муниципаль контрактлар шартларын үтәү, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, шундый юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә бюджет акчаларын урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү өлешендә.

10. Муниципаль контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләрне гамәлгә ашыралар:

1) тикшерүләр һәм ревизияләр (алга таба – контроль чаралар) үткәрәләр;

2) муниципаль контроль объектларына актлар, бәяләмәләр, язма гаризалар һәм (яки) күрсәтмәләр җибәрәләр;

3) Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе бюджет законнарының башка актлары нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган бюджет буенча мәҗбүр итү чараларын куллану турында карарлар кабул итүгә вәкаләтләнгән вазыйфаи затларга һәм органнарга бюджет буенча мәҗбүр итү чараларын куллану турында белдерү кәгазе җибәрәләр;

4) административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә хокук бозулар турындагы эшләр буенча производствоны гамәлгә ашыру өчен документлар җибәрәләр.

11. Муниципаль контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) язмача нигезле запрос буенча контроль чаралары үткәрү өчен кирәкле булган язмача яки телдән мәгълүмат, документлар һәм материаллар, аңлатмалар сорарга һәм алырга;

2) хезмәт таныклыкларын һәм контроль чара үткәрү турында Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгының (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) боерыгы күчермәсен күрсәтеп, үзләренә карата муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затлар били торган бүлмәләргә һәм территориягә тоткарлыксыз керергә, кайтарылган товарларны, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләрен күрсәтүне таләп итәргә;

3) контроль чаралар үткәргәндә кирәкле экспертизалар үткәрергә һәм (яки) шундый экспертизалар үткәрү өчен экспертларны җәлеп итәргә;

4) Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлар бозылудан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә килгән зыянны каплау турында дәгъва гаризасы белән судка мөрәҗәгать итү өчен документлар әзерләргә;

5) шәһәр прокуратурасы, дәүләт хакимияте органнары, муниципаль контроль органнары, эксперт оешмалары белән үзара эш итәргә.

12. Муниципаль контроль үткәргәндә вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә бурычлы:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә, мәҗбүри таләпләрнең бозылуын кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, муниципаль хокукый актларны, муниципаль контроль объекты хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) планлы тикшерү үткәрү көненә кадәр – өч эш көне алдан, планнан тыш тикшерү үткәрү көненә кадәр егерме дүрт сәгать алдан контроль объекты вәкиленә хәбәр итәргә;

4) муниципаль контрольне Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының аны үткәрү турындагы боерыгы нигезендә үткәрергә;

5) муниципаль контрольне хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта, күчмә тикшерүне хезмәт таныклыкларын күрсәтеп үткәрергә;

6) муниципаль контроль үткәргәндә муниципаль контроль объекты җитәкчесенә һәм (яки) башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә комачауламаска һәм муниципаль контроль предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

7) муниципаль контроль үткәргәндә катнашучы муниципаль контроль объекты җитәкчесенә һәм (яки) башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә муниципаль контроль предметына кагылышлы мәгълүмат һәм документларны бирергә;

8) муниципаль контроль объекты җитәкчесен һәм (яки) башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен муниципаль контроль нәтиҗәләре белән таныштырырга;

9) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль контроль объектлары тарафыннан аларга карата шикаять бирелгәндә, үз гамәлләренең нигезле булуын исбатларга;

10) контроль чаралар үткәрүнең Административ регламентта билгеләнгән срокларын үтәргә;

11) муниципаль контроль объектының вазыйфаи затыннан Россия Федерациясе законнарында тапшыру күздә тотылмаган документларны һәм башка мәгълүматларны таләп итмәскә;

11) күчмә тикшерү үткәрелә башлау алдыннан муниципаль контроль объекты җитәкчесенең һәм (яки) башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең соравы буенча аларны контроль чара үткәрүгә нигез булган Административ регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

12) тикшерү һәм ревизияләр актларын, бәяләмәләрне, язма гаризаларны һәм күрсәтмәләрне контроль объекты вәкиленә бирергә яисә тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән почта аша яки адресат тарафыннан аны алу датасын раслаучы башка ысул белән, шул исәптән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын кулланып

җибәрергә.

13. Вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) шундый таләпләр аларның вәкаләтләренә карамаган очракта, мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) планлы яки планнан тыш тикшерү муниципаль контроль объекты җитәкчесе һәм (яки) башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тарафыннан үткәрелсә һәм ул булмаган очракта аны гамәлгә ашырырга;

3) алар муниципаль контроль объекты булып саналмаган яки муниципаль контроль предметына карамаган очракта, документлар, мәгълүмат, үрнәкләр тапшыруны таләп итәргә, шулай ук шундый документларның төп нөсхәләрен алырга;

4) Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, муниципаль контроль нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт сере, закон нигезендә саклана торган башка сер булып саналган мәгълүматны таратырга;

5) контроль чаралар үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;

6) контроль чараларны муниципаль контроль объектлары хисабына үткәрергә.

14. Муниципаль контроль объекты җитәкчесе һәм (яки) башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле түбәндәгеләргә хокуклы;

1) контроль чара үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) муниципаль контроль органыннан һәм аның вазыйфаи затларыннан муниципаль контроль предметына караган мәгълүматны алырга;

3) муниципаль контроль нәтиҗәләре белән танышырга һәм үзенең муниципаль контроль нәтиҗәләре белән танышуын, алар белән, шулай ук вазыйфаи затларның аерым гамәлләре белән ризалашуы һәм ризалашмавы турында муниципаль контроль актында күрсәтергә;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә, контроль чаралар үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр хокукларын бозуга китергән вазыйфаи затларның эш итүләренә (эш итмәүләренә) административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә.

15. Муниципаль контроль объекты җитәкчесе һәм (яки) башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле түбәндәгеләргә бурычлы:

1) вазыйфаи затлар тарафыннан соралган документларны һәм материалларны, шулай ук муниципаль контроль предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача аңлатмалар бирергә;

2) күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларны һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларны, эксперт оешмалары вәкилләрен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда файдаланыла торган биналар, төзелмәләр, корылмалар, бүлмәләр территорияләренә, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдаланыла торган җиһазларга, транспорт чараларына һәм алар

тарафыннан тапшырыла торган йөкләр ягына керүен тәэмин итәргә;

3) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрүдә катнашырга яки алар өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә.

16. Планлы, планнан тыш контроль чаралары нәтиҗәләре буенча вазыйфаи затлар тарафыннан түбәндәге документлар төзелә:

1) контроль объектына карата тикшерү акты;

2) закон бозуны бетерү турында күрсәтмә (гариза) (бозу факты ачыкланган очракта);

3) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының бюджет буенча мәҗбүр итү чараларын куллану яки аларны куллану өчен нигезләр булмау турында боерыгы.

17. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен муниципаль контроль органына гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү нигез булып торган очракта, муниципаль контроль нәтиҗәләре буенча гариза бирүчегә «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

18. Контроль чараларның нәтиҗәләре буенча, тикшерүче затның эш итүләрендә (эш итмәүләрендә) гаепләнүче затка карата административ хокук бозу составы билгеләре булган очракта, хокук саклау органнарына документлар җибәрүне тәэмин итә.

Контроль чаралар үткәрү барышында җинаять билгеләре ачыкланган очракта, җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен аларның компетенцияләреннән чыгып, гаепләү ягыннан җинаять-суд эшләрен башкаруда катнашучылар адресына бюджет законнарын бозу белән бәйле материалларны җибәрү турында мәсьәлә хәл ителә.

## 2 бүлек. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибенә таләпләр

19. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында хәбәр итү тәртибе.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Хәсән Туфан проспекты, 23 нче йорт.

Башкарма комитетның эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга 08:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр.

Шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Белешмә өчен телефон: 8 (8552) 30 55 44.

Финанс идарәсенең урнашу урыны: Яр Чаллы шәһәре, Х. Туфан проспекты, 23 йорт, 376 кабинет.

Финанс идарәсенең белешмә өчен телефоны: 8 (8552) 30 55 44.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы мәгълүмат бирелә:

1) телефон элемтәсе чараларыннан файдаланып;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://nabchelny.ru;

3) электрон почта аша: nche.fbp@tatar.ru.

4) турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;

5) язма рәвештә (почта аша мөрәҗәгать иткәндә, Административ регламентның 20 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча).

20. Муниципаль функцияне үтәү мәсьәләләре буенча белешмәләр алу өчен телефон: 8 (8552) 30 55 44.

Мөрәҗәгатьләр жибәрү өчен электрон адрес: nche.fbp@tatar.ru.

Муниципаль контроль органына муниципаль функцияне үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 423805, Яр Чаллы шәһәре, Х. Туфан проспекты, 23 йорт.

21. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы мәгълүмат «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 21 апрелендәге 59-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә гражданнарны кабул итү гамәлгә ашырыла торган Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

22. Муниципаль контроль үткәрү өчен, шул исәптән контроль чаралар үткәрүгә экспертларны һәм эксперт оешмаларны җәлеп иткән очракта, аларның хезмәтләре өчен юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән түләү алынмый.

23. Муниципаль функцияне үтәү сроклары Административ регламентның 38-41 пунктларында билгеләнә.

24. Планлы контроль чаралары Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан раслана торган тиешле елга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча эшләр планы һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының аны билгеләү турында боерыгы нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш контроль чаралары Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла:

шәһәр Хакименең, Башкарма комитет Җитәкчесенең, хокук саклау органнарының йөкләмәләре, депутатларның запрослары, дәүләт органнарының, гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре кергән очракта, шулай ук Россия Федерациясе бюджет законнары бозылу билгеләре барлыкка килгән очракта;

Россия Федерациясе бюджет законнарын бозуның элек ачыкланган очракларын бетерүне контрольдә тоту өчен.

Финанс идарәсенә мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирмәүче мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук югарыда күрсәтелгән

фактлар турында мәгълүматларга ия булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен нигез була алмый.

25. Муниципаль контрольне үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар булып түбәндәгеләр тора:

1) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары:

2) финанс идарәсе башлыгы урынбасары;

3) финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы;

4) финанс идарәсенең бюджет сәясәте бүлеге башлыгы;

5) финанс идарәсенең хисап һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

6) финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлегенең баш белгечләре;

7) финанс идәрәсе бюджет бүлегенең баш белгечләре;

8) финанс идәрәсе хисап һәм хисаплылык бүлегенең баш белгечләре.

26. Вазыйфаи затларның персональ составы хезмәт бурычларыннан чыгып билгеләнә һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының боерыгы белән раслана.

Муниципаль контроль буенча чараларны муниципаль контроль үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар арасыннан контрольдә тоту төркеме, яисә муниципаль контроль үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар гамәлгә ашыра. Контрольдә тоту төркеменең җитәкчесе һәм секретаре Башкарма комиет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара үткәрү турындагы боерыгы белән билгеләнә.

27. Контроль чаралар үткәрүгә нигезсез рәвештә комачаулаучы, контроль чара үткәрүдән баш тартучы һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозуның ачыклангаң очракларын бетерү турында финанс идарәсе күрсәтмәсен (гаризасын) билгеләнгән срокта үтәмәүче муниципаль контроль объектының җитәкчесе һәм (яки) башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Финанс идарәсенең вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә үз функцияләрен һәм хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокуксыз гамәлләр кылган (гамәлләр кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепләнүче вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, финанс идарәсе шундый чаралар күрелгән көннән башлап ун эш көне эчендә язма рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә хәбәр итәргә бурычлы.

## 3 бүлек. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр

28. Муниципаль контроль үткәргәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләрнең исемлеге 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

Муниципаль контрольне үткәргәндә юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләрнең исемлеге

| Т/с | Мәҗбүри таләпләр | Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив хокукый актлар |
|---|---|---|
| 1. | бухгалтерлык (бюджет) хисаплылыгын төзү һәм бирүнең үз вакытында, тулы һәм дөрес булуы | Россия Федерациясе Бюджет кодексы; Россия Федерациясе Хезмәт кодексы; Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2010 елның 1 декабрендәге 157н санлы приказы |
| 2. | бухгалтерлык (бюджет) хисабын алып бару, бухгалтерлык (бюджет) хисабы счетлары буенча операцияләрне чагылдыруның һәм күрсәтелгән операцияләрне документаль рәсмиләштерүнең үз вакытында, тулы һәм төгәл булуы | |
| 3. | бюджет сметасын яки финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзү һәм үтәү | |
| 4. | эшчәнлек нәтиҗәләренең планлы (фаразлы) күрсәткечләрен үтәү, эшчәнлек нәтиҗәләренең фактик күрсәткечләренең планлы (фаразлы) күрсәткечләрдән тайпылу сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау | |
| 5. | аларны үзгәртә торган һәм Бердәм счетлар планының тиешле счетларында финанс нәтиҗәләренең күрсәтелгән операцияләре буенча алынган финанс булмаган, финанс активлар, йөкләмәләр, операцияләр хисабына карата мәҗбүри гомуми таләпләрне үтәү | |
| 6. | материаль кыйммәтләрне инвентаризацияләүне үткәрүгә карата таләпләр үтәлешен кертеп, төп чараларны һәм материаль кыйммәтләрнең сакланышын һәм хәрәкәтен тәэмин итү | |
| 7. | товар-материаль кыйммәтләр алуга бирелгән ышаныч язуларын файдалану | |
| 8. | финанс контроле объекты исеменнән түләү документларын һәм башка документларны имзалау хокукына ия вәкаләтле затларның имза, финанс контроле объектының мөһер оттискы үрнәкләре белән карточкалар рәсмиләштерү | |

| Т/с | Мәҗбүри таләпләр | Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив хокукый актлар |
|---|---|---|
| 9. | кассада булган акчаларның лимиты үтәлешен кертеп, касса дисциплиналарын, планлы рәвештә һәм көтмәгәндә акчаларны инвентаризацияләүне үткәрү срокларын үтәү | |
| 10. | бюджет акчаларының адреслылык принцибын һәм максатчан характерын үтәү | |
| 11. | муниципаль программаларны тормышка ашыру турында хисаплылыкның тулылыгы һәм дөреслеге | |
| 12. | юридик һәм физик затларга муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль йөкләмәне үтәү | |
| 13. | финанс контроле объектының дебитор һәр кредитор бурычларын булдырмау | |
| 14. | юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү килешүен үтәү | |
| 15. | бюджет инвестицияләрен бирү килешүен үтәү | |
| 16. | муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны гамәлгә ашырганда контракт системасы турында Федераль законда һәм бюджет законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәү | 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсенең 8 бүлеге |

## 4 бүлек. Контроль чаралар үткәргәндә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан бирелә торган документлар

29. Контроль чаралар үткәргәндә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге:

1) юридик затлар өчен учредитель документлары;

2) шәхесне раслаучы документ (физик зат өчен);

3) шәхси эшмәкәр буларак салым органында исәпкә кую турында таныклык;

4) беренчел бухгалтерлык документлары, шул исәптән түләү йөкләмәләре; аванс хисаплары; касса документлары, башкарылган эшләрнең актлары; күрсәтелгән хезмәтләрнең акты; товарларны кабул итү-тапшыру акты; КС-2; КС-3;

5) резерв фонд һәм муниципаль предприятиенең башка фондлары турында мәгълүмат;

6) муниципаль унитар предприятиенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары (программалары);

7) чыгым йөкләмәсе барлыкка килү нигезен раслаучы килешү;

8) бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы;

9) бухгалтерлык хисабы регистрлары;

10) контроль объектының хисап сәясәте.

## 5 бүлек. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

30. Муниципаль функцияне үтәү үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

1) контроль чараны планлаштыру һәм билгеләү;

2) контроль объектына хәбәр итү;

3) контроль чара үткәрү.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру блок-схемасы Административ регламентка 1 нче кушымта булып тора.

31. Контроль чараны планлаштыру һәм билгеләү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Контроль чараларны сайлап алу, түбәндәге критерийлардан чыгып, финанс идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль финанс контроле органы тарафыннан охшаш контроль чара үткәрелү вакытыннан соң узган чор дәвамлылыгы;

2) дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, бюджет керемнәренең баш администраторларыннан кергән, шулай ук сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларын анализлау нәтиҗәләре буенча ачыкланган кимчелек билгеләре булу турында мәгълүмат.

32. Контроль объектын тикшерү чоры – агымдагы чор (ай, квартал, ел) һәм (яки) агымдагы елдан алда килүче ел.

Контроль чаралар шул ук бер контроль объектына карата, шул ук мәсьәләләр буенча, оч елга бердән артмаган күләмдә үткәрелә.

33. Тикшерүләр һәм ревизияләр, планлаштырыла торган елдан алда килүче елның 25 декабреннән соңга калмый, Административ регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча төзелә һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының боерыгы белән раслана торган контроль чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

34. Еллык планга үзгәрешләр кертү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) контроль объектын ликвидацияләү, үзгәртеп оештыру;

2) каршы тора алмаслык хәлләр килеп чыкканда.

35. Еллык планга үзгәрешләр кертү Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

36. Планнан тыш контроль чаралар Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) шәһәр Хакименең, Башкарма комитет Җитәкчесенең, хокук саклау органнарының йөкләмәләре, депутатларның запрослары, дәүләт органнарының, гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре кергән очракта, шулай ук Россия Федерациясе бюджет законнары бозылу билгеләре барлыкка килгән очракта;

2) Россия Федерациясе бюджет законнарын бозуның элек ачыкланган очракларын бетерүне контрольдә тоту өчен.

Планнан тыш контроль чаралары нәтиҗәләре буенча төзелгән актлар, бәяләмәләр, язма гаризалар һәм күрсәтмәләр шундый контроль чара үткәрү срогының соңгы көненнән соңга калмый.

Контроль чараны үткәрү нигезе: Административ регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының аны үткәрү турында боерыгы.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара үткәрү турында боерыгын чыгару критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Планда әлеге контроль чара булу;

2) шәһәр Хакименең, Башкарма комитет Җитәкчесенең, хокук саклау органнарының йөкләмәләре, депутатларның запрослары, дәүләт органнарының, гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре кергән очракта, шулай ук Россия Федерациясе бюджет законнары бозылу билгеләре барлыкка килгән очракта;

3) Россия Федерациясе бюджет законнарын бозуның элек ачыкланган очракларын бетерүне контрольдә тоту.

Контроль чараны планлаштыру һәм билгеләү нәтиҗәсе:

1) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан расланган контроль чаралар үткәрүнең еллык планы;

2) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара билгеләү турында боерыгы.

37. Контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә турыдан-туры муниципаль контроль үткәрүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат, планлы тикшерүне үткәрү конснә кадәр өч эш коне алдан яки планнан тыш тикшерүне үткәрү конснә кадәр бер көн алдан, язма рәвештә контроль объекты вәкиленә хәбәр итә.

Нәтиҗә: Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзаланган һәм контроль объекты адресына җибәрелгән хәбәр.

38. Тикшерүне үткәрү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүне үткәргәндә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы белән билгеләнгән контроль объекты эшчәнлеге өлкәсенең торышын анализлау һәм бәяләү гамәлгә ашырыла.

Тикшерү (камераль һәм күчмә тикшерүләр, ревизияләр кысаларында үткәрелә торган тикшерүләрдән тыш) күчмә тикшерүләр өчен билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үткәрелә.

Тикшерүләр Административ регламент нигезендә камераль һәм күчмә тикшерүләр яки ревизияләр кысаларында үткәрелергә мөмкин.

Нәтиҗә: тикшерү үткәрү срогының соңгы көненнән соңга калмый, Административ регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча төзелә һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзалана торган бәяләмә. Бәяләмә имзаланган көннән башлап өч эш көне эчендә, ул муниципаль контроль объекты җитәкчесенә һәм (яки) башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә җибәрелә.

Тикшерү бәяләмәсе һәм башка материаллар, бәяләмә имзаланган көннән башлап 15 көн эчендә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан каралырга тиеш.

Тикшерү үткәрү йомгаклары буенча, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тикшерү яки ревизия үткәрүне билгеләргә хокуклы.

39. Камераль тикшерү үткәрү тәртибе.

Камераль тикшерү финанс идарәсенең урнашу урыны буенча, шул исәптән бюджет (бухгалтерлык) хисаплылыгы һәм каршы тикшерүләр барышында алынган мәгълүмат, документлар, материаллар нигезендә үткәрелә.

Күчмә тикшерү үткәргәндә соралган мәгълүмат, документлар һәм материаллар контроль объектының вазыйфаи затлары тарафыннан бирелмәү яки үз вакытында бирелмәү фактлары буенча, контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат Административ регламентка 5 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзи.

Охшатып ясалган, ялган әйберләр, үзләштерүләр, гаеп эшләр ачыкланган очракта һәм әлеге законга каршы гамәлләрне бетерергә кирәк булганда, контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат Административ регламентка 6 нчы кушымтада каралган форма буенча законга каршы гамәлләр ачыклану турында акт төзи.

Камераль тикшерү, контроль объектыннан мәгълүмат, документлар һәм материаллар алган көннән башлап 20 эш көне дәвамында, вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә.

Камераль тикшерү үткәргәндә, вазыйфаи затлар тарафыннан запрос җибәрелгән датадан башлап тикшерү объектының мәгълүмат, документлар һәм материаллар бирү датасына кадәр вакыт аралыгы, шулай ук каршы тикшерү һәм (яки) тикшерү үткәрелә торган вакыт аралыгы аны үткәрү срогына кертелми.

Камераль тикшерүләр үткәргәндә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының боерыгы буенча тикшерү гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Нәтиҗә: Административ регламентка 7 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзелә һәм камераль тикшерү үткәрү срогының соңгы көненнән дә соңга калмый, тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана.

Камераль тикшерү акты имзаланган көннән башлап өч эш көне эчендә муниципаль контроль объекты җитәкчесенә һәм (яки) башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә җибәрелә.

Контроль объекты, актны алган көннән башлап биш эш көне эчендә, камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актка язма рәвештә каршылык белдерергә хокуклы. Контроль объектының язма рәвештәге каршылыгы тикшерү материалларына теркәлә.

Камераль тикшерү акты, ул имзаланган көннән башлап 15 көн эчендә, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан каралырга тиеш.

Камераль тикшерү актын карау нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары түбәндәге карарларны кабул итә:

1) мәҗбүр итү чаралары куллану турында;

2) мәҗбүр итү чаралары куллану өчен нигезләр булмау турында.

40. Күчмә тикшерү үткәрү тәртибе.

Күчмә тикшерү контроль объекты урнашкан урын буенча үткәрелә.

Үткәрү срогы: 30 эш көненнән артык түгел.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тикшерү төркеме җитәкчесенең дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә, күчмә тикшерү үткәрү срогын 10 эш көненнән артмаган срокка озайтырга мөмкин.

Күчмә тикшерү үткәргәндә соралган мәгълүмат, документлар һәм материаллар контроль объектының вазыйфаи затлары тарафыннан бирелмәү яки үз вакытында бирелмәү фактлары буенча, контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат Административ регламентка 5 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзи.

Охшатып ясалган, ялган әйберләр, үзләштерүләр, гаеп эшләр ачыкланган очракта һәм әлеге законга каршы гамәлләрне бетерергә кирәк булганда, контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат

Административ регламентка 6 нчы кушымтада каралган форма буенча законга каршы гамәлләр ачыклану турында акт төзи.

Контрольдә тоту төркеме җитәкчесенә яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затка контроль объекты территориясенә яки бүлмәсенә керү тоткарлыгы булганда, Административ регламентка 8 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзелә.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары контрольдә тоту төркеме җитәкчесенең яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә түбәндәгеләрне билгеләргә мөмкин:

1) тикшерү үткәрү;

2) каршы тикшерү үткәрү.

Тикшерү нәтиҗәләре нигезендә Административ регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча, күчмә тикшерү материалларына теркәлә торган бәяләмә рәсмиләштерелә.

41. Күчмә тикшерү барышында контроль объекты эшчәнлеген документаль һәм фактик өйрәнү буенча контроль гамәлләр башкарыла. Документаль өйрәнү буенча контроль гамәлләр контроль объектының финанс, бухгалтерлык, хисап документларына, сатып алуларны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру турындагы документларына һәм башка документларына карата, шулай ук, контроль объектының вазыйфаи, материаль җаваплы һәм башка затларының телдән һәм язмача аңлатмалары, белешмәләре һәм мәгълүматлары буенча мәгълүматны исәпкә алып, алардан алынган мәгълүматны анализлау, бәяләү һәм контроль буенча башка гамәлләрне башкару юлы белән үткәрелә. Фактик өйрәнү буенча контроль гамәлләр тикшерү, инвентаризацияләү, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза, контроль үлчәүләр һәм контроль буенча башка гамәлләрне башкару юлы белән үткәрелә.

Күчмә тикшерүне үткәрү, контрольдә тоту төркеме җитәкчесенең яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан туктатылырга мөмкин:

1) каршы тикшерү һәм (яки) тикшерү үткәрү чорында;

2) контроль объектының бухгалтерлык (бюджет) хисабы булмаганда яки канәгатьләнмәслек торышта булганда – контроль объекты тарафыннан күчмә тикшерү үткәрү өчен кирәкле документларны торгызу, шулай ук контроль объекты тарафыннан хисап һәм хисаплылык документларын тиешле хәлгә китерү чорында;

3) экспертизалар оештыру һәм үткәрү чорында

4) компетенцияле органнарга җибәрелгән запросларны үтәү чорында;

5) контроль объекты тарафыннан мәгълүмат, документлар һәм материаллар бирелмәгән һәм (яки) таләп ителә торган мәгълүмат, документлар һәм материаллар тулы булмаган комплектта бирелгән, һәм

(яки) контроль чара үткәрү тоткарланган, һәм (яки) контроль чара үткәрүдән качарга тырышкан очракта;

6) кирәк булганда контроль объектының урнашу урыны буенча булмаган милкәтне һәм (яки) документларны тикшергәндә.

Күчмә тикшерүне үткәрү туктатылган вакытта аның срогының дәвамлылыгы өзелә:

1) контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан күчмә тикшерү үткәрүне туктату турында боерык чыгарылган көннән башлап өч эш көне эчендә, тикшерү үткәрүне туктату турында һәм туктату сәбәпләре турында язма рәвештә контроль объектына хәбәр итә.

2) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, күчмә тикшерүне туктату сәбәпләре бетерелү турында мәгълүматлар алынган көннән башлап өч эш көне эчендә, күчмә тикшерү үткәрүне яңадан башлау турында боерык чыгара.

Контрольдә тоту төркеме җитәкчесе яисә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының күчмә тикшерү үткәрүне яңадан башлау турында боерыгы чыккан көннән башлап өч эш көне эчендә, контроль объектына күчмә тикшерү үткәрүне яңадан башлау турында хәбәр итә.

Нәтиҗә: күчмә тикшерү үткәрү срогының соңгы көненнән соңга калмый, Административ регламентка 7 нче кушымтада каралган форма буенча төзелә һәм тикшерүне үткәрүче вазыйфаи зат тарафыннан имзалана торган акт.

Күчмә тикшерү актына контроль чараларны үткәрү барышында алынган документлар, экспертиза (тикшерү) нәтиҗәләре, фото-, видео- һәм аудиоматериаллар теркәлә.

Күчмә тикшерү акты, ул имзаланган көннән башлап өч эш көне эчендә, муниципаль контроль объекты җитәкчесенә һәм (яки) башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә җибәрелә.

Контроль объекты, актны алган көннән башлап биш эш көне эчендә, күчмә тикшерү актына язма рәвештә каршылык белдерергә хокуклы. Контроль объектының язма рәвештәге каршылыгы күчмә тикшерү материалларына теркәлә.

Күчмә тикшерү акты, ул имзаланган көннән башлап 15 көн эчендә, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан каралырга тиеш.

Күчмә тикшерү актын һәм башка материалларны карау нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары түбәндәге карарларны кабул итә:

1) бюджет буенча мәҗбүр итү чаралары куллану турында;

2) бюджет буенча мәҗбүр итү чаралары куллану өчен нигезләр булмау турында.

42. Административ процедураларны электрон рәвештә башкару гамәлгә ашырылмый.

43. Бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары:

1) күрсәтелгән документта билгеләнгән срокларда яки срок күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән башлап 30 календарь көн эчендә мәҗбүри каралырга тиешле, Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актларны, бюджеттан акчалар бирү турында килешүләр (килешенүләр), муниципаль контрактлар, шулай ук күрсәтелгән килешүләрне (килешенүләрне) үтәү максатында төзелгән контрактлар (килешүләр, килешенүләр) һәм муниципаль контрактлар шартларын үтәү, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, контроль объектының кыйммәтле кәгазьләренә бюджет акчаларын урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозу очраклары ачыклану турында мәгълүматны үз эченә алган язма гаризаларны, шулай ук шундый бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын бетерү буенча чаралар күрү турындагы таләпне яки бирелгән бюджет акчаларын кире кайтару турындагы таләпне юллый;

2) күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта үтәү өчен, Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актларны, бюджеттан акчалар бирү турында килешүләр (килешенүләр), муниципаль контрактлар, шулай ук күрсәтелгән килешүләрне (килешенүләрне) үтәү максатында төзелгән контрактлар (килешүләр, килешенүләр) һәм муниципаль контрактлар шартларын үтәү, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, контроль объектының кыйммәтле кәгазьләренә бюджет акчаларын урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозуларны бетерү турында мәҗбүри таләпне үз эченә алган Россия Федерациясе бюджет законнарын бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне һәм (яки) муниципаль берәмлеккә китерелгән зыянны каплау турындагы таләпне юллый;

3) бюджет буенча мәҗбүр итү чаралары кулланa.

44. Язма гаризалар һәм күрсәтмәләр контроль чара тәмамланган көннән башлап 5 эш көне эчендә контроль объекты вәкиленә җибәрелә.

45. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының язма гаризасы яки күрсәтмәсе белән килешмәгән очракта, контроль объекты җитәкчесе суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

46. Контроль чара кысаларында финанс идарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан төзелә торган барлык документлар контроль чара материалларына теркәлә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Хезмәт регламентында билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып исәпкә алына һәм саклана.

47. Хисап календарь елы өчен контроль чаралары планын тулысынча һәм үз вакытында үтәү турындагы мәгълүматны ачыклау, контроль эшчәнлеге нәтиҗәлелеген тәэмин итү, шулай ук контроль чараларны үткәрү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны анализлау максатында финанс идарәсе, ел саен контроль чараларның темалары, тикшерелгән контроль объектлары һәм тикшерелә торган чорлар буенча төркемләнә торган контроль чаралар үткәрү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны чагылдырып хисап төзи.

Хисап рәвешендә мәҗбүри ачыкланырга тиешле контроль чаралар үткәрү нәтиҗәләренә түбәндәгеләр керә:

1) кимчелекләрнең төрләренә карап, сан буенча һәм акчалата чагылышта исәпләнгән штрафлар;

2) хокук саклау органнарына җибәрелгән материалларның саны һәм кимчелекләрнең төрләре буенча күздә тотылган зыянның суммасы;

3) язма гаризаларның һәм күрсәтмәләрнең саны һәм аларны сан буенча һәм (яки) акчалата чагылышта үтәү, шул исәптән язма гаризалар һәм күрсәтмәләр буенча торгызылган (кайтарылган) средстволарның күләме;

4) күрелгән һәм үтәлгән (үтәлмәгән) бюджет буенча мәҗбүр итү чараларының саны;

5) тикшерелгән бюджет акчаларының күләме;

6) Җитәкче урынбасары карарларына, шулай ук аның тарафыннан гамәлгә ашырылган контроль эшчәнлеге кысаларында аның эш итүләренә (эш итмәүләренә) карата бирелгән һәм (яки) канәгатьләндерелгән шикаятьләр (дәгъвалар) саны.

Хисап Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзалана һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшырыла.

Контроль чараларны үткәрү нәтиҗәләре «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, шулай ук сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## 6 бүлек. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

48. Контроль чараларда катнашучы вазыйфаи затлар контроль объектлары тарафыннан язма гаризаларның һәм күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыралар, муниципаль контрольне үткәрү барышында вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алалар, тиешле хезмәт тикшерүләре үткәрәләр һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә шундый вазыйфаи затларга карата чаралар күрәләр.

49. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

50. Үткәрелгән контроль чаралар нәтиҗәләре буенча, муниципаль функцияне үтәгәндә вазыйфаи затлар тарафыннан җибәрелгән кимчелекләр ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавапка тартылалар. Шул ук вакытта ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелә.

51. Муниципаль функцияне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, муниципаль функцияне үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарлар һәм эш итүләр (эш итмәүләр) өчен җавап тоталар.

## 7 бүлек. Муниципаль функцияне үтәүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

52. Муниципаль контроль объекты җитәкчесе һәм (яки) вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, башка кызыксынучы затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерү үткәргәндә муниципаль контроль объекты хокукларын бозуга китергән, муниципаль контроль органы, аның вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль функцияне үтәү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирергә хокуклы.

53. Муниципаль контроль органының, аның вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияне үтәү барышында кабул иткән яки гамәлгә ашырган карарлары яки эш итүләре (эш итмәүләре) тора.

54. Алар компетенциясе нигезендә муниципаль контроль органына яки вазыйфаи затка кергән шикаять мәҗбүри каралырга тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне караудан баш тарту яки карауны туктату өчен нигезләр каралмаган.

55. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми:

1) әгәр язмача шикаятьтә шикаять белән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә законга каршы әзерләнгән, эшләнә торган яки эшләнгән эшләр, шулай ук аны әзерләүче, эшләүче яки эшләгән зат турында мәгълүматлар булса, шикаять аның компетенциясе чикләрендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш);

2) әгәр шикаятьтә әдәпсез яисә мыскыллы гыйбарәләр, эчке муниципаль финанс контроле буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса (муниципаль контроль

органының вазыйфаи заты шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хокукны явыз ниятгә файдалану рөхсәт ителмәү турында хәбәр итәргә хокуклы);

3) әгәр язмача шикаять тексты укырлык булмаса (күрсәтелгән шикаять шулай ук карап тикшерү өчен аларның компетенциясе чикләрендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш түгел), бу хакта шикаять теркәлгән көннән башлап җиде көн эчендә шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), почта адресы укырлык дәрәҗәдә булса;

4) әгәр гариза бирүченең шикаятендә аның элек җибәрелгән шикаятьләренә берничә тапкыр нигезле җаваплар бирелгәннән соң да шикаятьтә яңа хәбәрләр яки хәлләр китерелмәгән сорау булса (әлеге шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки бер үк вазыйфаи затка юлланган булса, (шикаять җибәрүчегә язышуны туктату карары турында хәбәр ителә);

5) әгәр шикаятьтә куелган сорау буенча нигезле җавап дәүләт яки башка федераль закон белән саклanучы сер булган мәгълүматларны таратмыйча бирелә алмаса (шикаять җибәрүчегә анда куелган сорауга күрсәтелгән мәгълүматларны тарату ярамау сәбәпле, нигезле җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә).

56. Муниципаль контроль органының, аның вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып муниципаль контроль органына шәхсән гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) яки почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән муниципаль контроль органының рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә шикаять керү тора.

57. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы. Әлеге төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр муниципаль контроль органы адресына язма рәвештә тиешле запрос җибәрергә тиеш. Житәкче, җаваплы башкаручылар, запрос теркәлгән көннән башлап утыз календарь көн эчендә, соралган мәгълүматларны һәм документларны бирергә тиеш.

58. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять муниципаль контроль органы җитәкчесенә җибәрелергә мөмкин. Муниципаль контроль органының һәм муниципаль контроль органы җитәкчесенең эш итүләре (эш итмәүләре) буенча шикаять Башкарма комитетка җибәрелергә мөмкин.

59. Муниципаль контроль органына яки муниципаль контроль органының вазыйфаи затына, аларның компетенциясе чикләрендә кергән шикаять, ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көненнән артмаган срокта карап тикшерелә.

Җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат, шикаятьне карап тикшерүче җирле үзидарә органының яки вазыйфаи затның билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән запросы буенча шикаятьне карап тикшерү өчен кирәкле документларны һәм материалларны биш эш көне эчендә бирергә тиеш (дәүләт яки башка федераль закон белән саклanучы сер булган мәгълүматларга ия һәм аларны бирүнең аерым тәртибе билгеләнгән документлардан һәм материаллардан тыш).

Аерым очракларда, шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән запрос җибәрелгән очракта вазыйфаи зат яисә шуңа вәкаләтле зат, шикаятьне җибәрүчегә аны карап тикшерү срогы озайтылу турында хәбәр итеп, шикаятьне карап тикшерү срогын өч эш көненнән артмаган срокка озайтырга мөмкин.

60. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль функцияне үтәү барышында эш итүләргә (эш итмәүләргә) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, атап әйткәндә:

тикшерү барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, аларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чара күрү;

Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаепле җаваплы башкаручыларга карата күрелгән чаралар турында, шундый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язма рәвештә хәбәр итү;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә әлеге карарның дәлилләнгән нигезле булуын язма рәвештә хәбәр итеп, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда эш итүләргә (эш итмәүләргә) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру. Муниципаль контроль органына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятькә җавап шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

61. Муниципаль контроль органы шикаятьне карап тикшерү өчен, мөрәҗәгать итүчедән муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының нигезсез эш итүләрен раслаучы беренчел документларны, шул исәптән электрон рәвештә соратып алырга хокуклы.

Соралган материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан запрос кергән датадан башлап өч эш көне эчендә бирелергә тиеш.

62. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының эш итүләре (эш итмәүләре) нәтиҗәсендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә китерелгән зыян Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә урынсыз дип табылса, Россия Федерациясе законнары нигезендә, килми

калган файданы (алынмаган табышны) да кертеп, муниципаль бюджет акчалары хисабына кире кайтарылырга тиеш.

63. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләреннән риза булмыйча, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирелергә мөмкин.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Эчке муниципаль финанс
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
1 нче кушымта

## Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның блок-схемасы

Вазыйфаи зат

| Контроль чараны сайлап алуны гамәлгә ашыра | Контроль чаралар планы |
|---|---|

Вазыйфаи зат

| Планлы тикшерү үткәрү көненә кадәр өч эш көне алдан яки планнан тыш тикшерү үткәрү көненә кадәр бер көн алдан, язма рәвештә контроль объекты вәкиленә хәбәр итә | хәбәр |
|---|---|

Вазыйфаи зат

| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара билгеләү турында боерыгын әзерли | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара билгеләү турында боерыгы |
|---|---|

Вазыйфаи зат

| | |
|---|---|
| Контроль объектына карата контроль чара (тикшерүләр, ревизияләр) үткәрә | Акт, гариза, күрсәтмә |

Вазыйфаи зат

| | |
|---|---|
| Үткәрелгән контроль чаралар нәтиҗәләренең үтәлешен контрольдә тота | Контроль чаралар турында хисап |

Эчке муниципаль финанс
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты финанс идарәсенең
юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерү буенча еллык планы

Расланган:
Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы

__________ ______________________________
(финанс идарәсе җитәкчесенең Ф.И.А.и.)
«_____» _________________ 20___ ел

__________ елга юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерү үткәрү
ПЛАНЫ

| Эшчәнлеге тикшерелергә тиешле юридик затның, шәхси эшмәкәрнең исеме | Эшчәнлеге тикшерелергә тиешле юридик затның, шәхси эшмәкәрнең исеме, урнашу урынының адресы | Салым түләүченең идентификация номеры | Тикшерүне үткәрү максаты | Тикшерү үткәрү нигезе | | Тикшерүне үткәрә башлау датасы | Планлы тикшерүне үткәрү срогы | Тикшерүне үткәрү формасы (документар, күчмә, документар һәм күчмә) | Контроль чараны үткәрә торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының, муниципаль контроль органының исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | соңгы тикшерүнең тәмамлану датасы | юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау датасы | | эш көннәре | | |
| | | | | | | | | | |

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына 3 нче кушымта

________________________________
________________________________
________________________________
________________________________
(контроль объектының исеме)

карата планлы (планнан тыш) күчмә (камераль) тикшерү үткәрү турында

1. ____________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
(контроль объектының исеме)

карата тикшерү үткәрергә.

2. Контроль объектының урнашу урыны: ________________________

3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затлар итеп билгеләргә:

1) __________________________________________________________;

2) __________________________________________________________.

4. Тикшерү үткәрүгә экспертлар, эксперт оешмаларның вәкилләре буларак түбәндәге затларны җәлеп итәргә: җәлеп ителәләр (җәлеп ителмиләр).

5. Әлеге тикшерү эчке муниципаль финанс контроле кысаларында үткәрелә.

6. Билгеләргә:

1) әлеге тикшерү ______________________ максатында үткәрелүне;

2) түбәндәгеләрне карау:

1) __________________________________________________________;

2) __________________________________________________________

әлеге тикшерүнең бурычы булып торуны.

7. Әлеге тикшерүнең предметы булып муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) таләпләрне үтәү тора.

8. Тикшерүне үткәрү срогы: 2018 елның 22 гыйнварыннан 5 мартына кадәр.

9. Тикшерүне үткәрүнең хокукый нигезләре:

1) __________________________________________________________;

2) __________________________________________________________.

10. Тикшерелергә тиешле муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләр һәм (яки) таләпләр:

1) __________________________________________________________;

2) __________________________________________________________.

11. Тикшерү процессында тикшерүне үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле түбәндәге контроль чараларны үткәрергә (контроль буенча чараларның исемнәрен һәм аларны үткәрү срокларын күрсәтеп):

1) ______________________________;

2) ______________________________.

12. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезнамәләр, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар исемлеге (булган очракта):

1) ______________________________;

2) ______________________________.

13. Тикшерүне үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге:

1) ______________________________;

2) ______________________________.

Финанс идарәсе
җитәкчесе имза имзаның расшифровкасы

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына 4 нче кушымта

Бәяләмә №__________

____________________ ел

________________________________________ нигезендә

(Башкарма комитет Житәкчесе урынбасары боерыгының реквизитлары)

________________________________________ карата

(контроль объекты)

________________________________________ үткәрелде.

(контроль чара)

Тикшерү үткәрү турындагы боерык/приказ күчермәсе белән таныштырылды:
(күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла)

________________________________________

________________________________________

(фамилияләр, инициаллар, имза, дата, вакыт)

Тикшерүне үткәрүче затлар:
1) ________________________________________
2) ________________________________________

Тикшерү барышында түбәндәге мәсьәләләр каралды:
1) ________________________________________
2) ________________________________________

Тикшерүне үткәрү барышында мәжбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актлар ((норматив) хокукый актларның нигезләмәләрен күрсәтеп) белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланды яки ачыкланмады

________________________________________

________________________________________

________________________________________

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә түбәндәге чараларны күрергә:
1) ________________________________________
2) ________________________________________

Бәяләмәгә теркәлгән документлар: юк
Тикшерүне үткәргән затларның имзалары: ____________________

Бәяләмә белән таныштым, барлык кушымталары белән бергә акт күчермәсен алдым:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(юридик зат житәкчесенең, банка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы)

"__" _______________ 20__ ел

____________________

(имза)

Бәяләмә белән танышудан баш тарту турында билге: ____________________

(тикшерүне үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзалары)

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына 5 нче кушымта

Контроль чара уткәргәндә
контроль объектлары тарафыннан мәгълүмат бирмәү турында
АКТ

«___» _______________ 20__ ел ____________________________

(актны төзү датасы) (актны төзү урыны)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________ нигезендә

(реквизитлары (номеры, датасы) күрсәтелгән документның төре, эчке муниципаль финанс контролен тикшергән органның исеме)

Контроль чара уткәргәндә түбәндәге соралган документлар тапшырылмады:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Документларны тапшырмау сәбәпләре:

________________________________________________________________________

Контроль чара уткәргән затларның имзалары:

Тикшерелә торган оешма вәкилләренең имзалары:

Тикшерү акты белән таныштым, барлык кушымталары белән акт күчермәсен алдым: ____________________

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына 6 нчы кушымта

Контроль чара объектының документларын алу турында
АКТ

__________ «   » ________ 20__ ел

______________________________________________

______________________________________________ нигезендә
(Контроль чараларның эш планының пункты, планнан тыш контроль чарасын үткәрү өчен башка нигезләр)

______________________________________________ объектында
(контроль чара объектының исеме)

______________________________________________
(контроль чараның исеме)
контроль чара үткәрелә.

Түбәндәгеләр нигезендә: ______________________

Тикшерү өчен түбәндәге документлар алынды:
1. ______________________ ____ биттә
2. ______________________ ____ биттә
3. ______________________ ____ биттә

Документларны алу түбәндәге вазыйфаи затлар катнашында башкарылды______________
______________________________________________
(контроль чара объектының исеме, вазыйфа, фамилия һәм инициаллар)
______________________________________________

Әлеге Акт ике нөсхәдә төзелде, танышу өчен бирсе ______________________
______________________________________________
(тикшерелә торган объектның вазыйфаи заты, фамилиясе һәм инициаллары)
______________________________ тапшырылды (җибәрелде).

Контроль чараның
җитәкчесе

______________ ______________ ______________
(вазыйфасы) (шәхси имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

Актның бер нөсхәсен алды

______________ ______________ ______________
(вазыйфасы) (шәхси имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

Эчке муниципаль финанс
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
7 нче кушымта

# ТИКШЕРҮ АКТЫ №_____

______________________________________________________________ нигезендә
(Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгының реквизитлары)

______________________________________________________________ карата
(контроль объекты)

______________________________________________________________ үткәрелде.
(контроль чара)

Тикшерүне үткәрү датасы һәм вакыты:

«__» ___ 20__ел, __сәг.__минуттан __сәг.__минутка кадәр. Дәвамлылыгы ___
«__» ___ 20__ел, __сәг.__минуттан __сәг.__минутка кадәр. Дәвамлылыгы ___
Тикшерүнең гомуми дәвамлылыгы: 22 эш көнс дәвамында.
Акт төзелде: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының финанс идарәсе тарафыннан
Тикшерү турында боерыкның/приказның күчермәсе белән таныштырылды: (күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла)

______________________________________________________________

______________________________________________________________
(фамилияләр, инициаллар, имза, дата, вакыт)

Тикшерүне үткәргән затлар:
1) ______________________________________________________
2) ______________________________________________________

Тикшерүне үткәрү барышында мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актлар ((норматив) хокукый актларның нигезләмәләрен күрсәтеп) белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланды яки ачыкланмады

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан үткәрелә торган юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүләрне исәпкә алу журналына язып куелды (күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла)
Актка теркәлгән документлар: юк

Тикшерүне үткәргән затларның имзалары: ____________________

Тикшерү акты белән таныштым, барлык кушымталары белән акт күчермәсен алдым:

_______________________________________________

_______________________________________________

(юридик зат житәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы)

«__» ______________ 20__ ел

_______________________

(имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге: ______________

(тикшерүне үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзалары)

Эчке муниципаль финанс
контролен гамәлгә ашыруның
административ регламентына
8 нче кушымта

Контроль чара үткәрүдә җаваплы вазыйфаи затларга
каршылык тудыручы фактлар турында
АКТ

__________________ «___» __________ 20__ ел

____________________________________________

____________________________________________ нигезендә
(Контроль чараларның эш планының пункты, планнан тыш контроль чарасын үткәрү өчен башка нигезләр)

____________________________________________ объектында
(контроль чара объектының исеме)

____________________________________________
(контроль чараның исеме)

контроль чара үткәрелә.

Күрсәтелгән контроль чараны үткәргәндә,

____________________________________________
(контроль чара объектының исеме,

____________________________________________ вазыйфаи затлары тарафыннан
(затларның вазыйфасы, инициаллары һәм фамилияләре)

Башкарма комитетның финанс идарәсе хезмәткәрләренә

____________________________________________
(чараны үткәрү өчен каршылыклар тудыруның конкрет фактлары күрсәтелә – Башкарма комитет финанс идарәсе хезмәткәрләренә объектка керүгә рөхсәт итмәү, мәгълүмат бирмәү)

____________________________________________ дә чагылдырылган каршылыклар тудырылды.

Әлеге Акт ике нөсхәдә төзелде, танышу өчен берсе ____________________

____________________________________________
(тикшерелә торган объектның вазыйфаи заты, фамилиясе һәм инициаллары)

____________________________________________ тапшырылды (җибәрелде).

Контроль чараның
җитәкчесе

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
| (вазыйфасы) | (шәхси имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

Актның бер нөсхәсен алды

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
| (вазыйфасы) | (шәхси имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |